Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге
Рус Богдашкиносы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«6» ноябрь 2020 ел № 1

1. Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 6 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 гр инвалидларыннан тыш(I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта), балачактан инвалид булганнардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Рус Богдашкино авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш һәм грунт катнашмасы салу (сатып алу, ташу, җәю);

Урам утларын ремонтлау һәм карап тоту (кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре);

Зиратны төзекләндерү (хуҗалык блогын ремонтлау, килешү буенча башкарылган эшләр өчен түләү)» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 329 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 195 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 195 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 гр инвалидларыннан тыш(I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта), балачактан инвалид булганнардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Рус Богдашкино авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән  сезонлы карап тоту һәм вак таш һәм грунт катнашмасы салу (сатып алу, ташу, җәю) мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныргa;

Урам утларын ремонтлау һәм карап тоту (кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре) мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныргa;

Зиратны төзекләндерү (хуҗалык блогын ремонтлау, килешү буенча башкарылган эшләр өчен түләү) мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Рус Богдашкиносы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А. Л. Михайлова

Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А. Л. Михайлова